Кукморский муниципальный район

Конкурс профессионального мастерства
работников сферы воспитания и дополнительного образования
«Воспитать человека»

Номинация «Управление воспитательным процессом»

# Тәрбия системасының белем бирүдә кыйммәте

Заместитель директора
по воспитательной работе
СОШ с.Маскара им.Н.А.Самигуллина

Хамидуллина Гузель Мохлисулловна

Белем бирү белән тәрбия системасы бербөтен. Бу ике төшенчәне берберсеннән берничек тә аерып булмый. Гимназиядә тәрбия эше балаларның шәхес буларак үсешенә юнәлтелгән. Укытучы-тәрбияченең, сыйныф җитәкчесенең эш системасы бала шәхесенең үсешенә, иҗади сәләтен ачуга һәм аны үстерүгә юнәлтелгән булырга тиеш. Педагогик эшчәнлектә - иҗади активлык, танып-белү активлыгы, танып–белү мөстәкыйльлеге, иҗади сәләт, иҗади эшчәнлек, новаторлык дигән сүзләр төп педагогик терминнар булып торалар. Башкача була да алмый. Кеше актив эшчәнлек ихтыяҗына мохтаҗ булып туа, әмма генетик яктан нигезләнгән сәләт бары тик белем һәм тәрбиянең уңай шартларында гына киң үсеш ала. Фәннәр буенча үткәрелгән бәйгеләр сәләтле укучылар белән эшләү мөмкинчелекләрен ачалар. Укучы шәхесе шул фән буенча специальләшә, киләчәктә аңа үз тормышын да шул юнәлештә сайлау мөмкинлеге туа. Фән, спорт һ.б. түгәрәкләр баланың иҗади сәләтләрен үстерергә ярдәм итә, танып-белү эшчәнлеген арттыра, кызыксыну уята. Толерант шәхес тәрбияләүдә боларның барысының да әһәмияте зур. Укыту һәм тәрбия концепциясендә түбәндәгеләргә өстенлек бирү сорала:

- шәхеснең үзүсешендә психологик-педагогик ярдәм итү;
- шәхеснең укучыдан өлкән кешегә әверелү траекториясен күзәтү;
- гаилә тәрбиясе моделен формалаштыру.

Мәктәп белән гаиләнең хезмәттәшлеген ныгытуга игътибарны арттыруны заман үзе таләп итә. Баланы укыту һәм тәрбияләү процессының эффектлылыгы гаилә белән мәктәпнең тыгыз хезмәттәшлегеннән, килешеп эшләүләреннән тора. Белем бирү оешмасындагы тәрбия системасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге, педагог белән беррәттән, ата-аналарның да белем бирү процессы субъектына әверелүе белән характерлана.

1. Сыйныф һәм мәктәптән тыш үткәрелгән чараларда ата-аналарны катнаштыру.
2. Тәрбия өлкәсендә килеп туган актуаль проблемалар туганда ата-аналарны чакыру, бергәләп чишү юлларын эзләү.

3. Бала тәрбияләдә гаилә белән мәктәпнең тыгыз хезмәттәшлеген булдыру, аны бер системага салу.

Тәрбия системасын тормышка ашыруда түбәндәге максатлар куела:

1. Бала шәхесен өйрәнү (шәхси һәм үсеш үзенчәлекләрен; нәрсә белән кызыксына; сәләтен ачу, аны үстерү).
2. Укучыларның кызыксыну (интерес) юнәлешләрен өйрәнү һәм анализлау.
3. Өстәмә белем бирү педагоглары, психолог, социаль педагог, предмет укытучылары белән тыгыз хезмәттәшлек.
4. Укучыларның гаиләсе белән аралашу, алар белән индивидуаль эш.
5. Балалар оешмасы эшен киң җәелдерү.
6. Бала шәхесенең үсешен күрсәткән паспорт булдыру.

Тәрбияче, укытучы баланы мәҗбүр итеп берни эшләтә алмый, аны кызыксындыру юлларын эзләү кирәк. Тәрбиянең нәтиҗәлелеген арттыру өчен укучының танып-белү эшчәнлеген, кешелеккә мөнәсәбәтен, иҗадилык һәм әхлакка басым ясарга кирәклеге һәркемгә билгеле. Укучыларның теге яки бу түгәрәккә йөрүләрен тиешле дәрәҗәгә җиткерергә кирәк. Сыйныф җитәкчеләренең предмет укытучылары белән тыгыз элемтәдә торуы зарур. Укучыларның тәртибе, өлгереше, дәрескә әзерләнү-әзерләнмәве турында һәрчак хәбәрдар булу кирәк. Сыйныфларда укучы шәхесен өйрәнү өчен төрле тематик диагностикалар, тестлар үткәрергә мөмкин. Сыйныфта тәрбия системасын булдыру укучы шәхесен өйрәнгәннән соң гына мөмкин эш. Сыйныфта һәм гимназиядә булдырылган тәрбия системасы эше укучыларда гомумкешелек кыйммәтләрен булдыруга нигезләнә. Бәхетле, югары әхлаклы, иҗади, уйларга сәләтле, тирә-юньне, үзен әйләндереп алган мөхитне аңлый белүче шәхес тәрбияләү - безнең төп максат. Укучылар коллективын теге яки бу өлкәдә, уку, физик, хезмәт, әхлакый тәрбия эшчәнлеге нәтиҗәсе туплый. Балалар оешмасы (Эзтабарлар, Варислар, Балалар Думасы) укучыларда

тормыш позициясен билгеләргә ярдәм итә. Класс һәм мәктәп үзидарәсендә әгъза булып торучы укучылар тигез хокуклы, үзләренең тәртипләре өчен җаваплы, теге яки бу өлкәдә шәхси эш алымнарын кулланалар. Класс җыелышлары даими үтә, аны, әлбәттә, укучылар үзләре алып бара. Минем карашымча, укытучы-тәрбияче түбәндәгеләрне төгәл үтәргә тиеш:

1. Укучыларның дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлектә интеллектуаль үсешләрен тәэмин итәргә.
2. Балалар оешмасы аша укучыларның танып-белү эшчәнлеген арттырырга, иҗади сәләтләрен үстерергә.
3. Өстәмә беләм бирү педагоглары белән тыгыз хезмәттәшлектә булырга.
4. Классның һәм мәктәп-гимназиянең үзидарә эшчәнлегенә тартырга.

Укытучы-тәрбияче исендә тотарга тиеш:

1. Укучы шәхесен өйрәнү аша, аның интересларын яклап, дөрес юнәлеш бирү.
2. Һәр бала – сәләтле. Аңа коллективта үз урынын табарга ярдәм итү, сәләтен үстерү.
3. Һәр бала үзен кирәкле итеп тойсын өчен аңа шатлык хисен кичерергә ярдәм итү.
4. Толерантлык тәрбияләү. Тормышка үз карашын булдыру, тирә-якта авырлыкларга бирешмичә үз дәрәҗәсен яуларга, сабыр, түземле булырга өйрәтү.

Төп белемне, әлбәттә, бала дәрестә ала. Тәрбия системасы укучыларның интеллектуаль үсешенә зур йогынты ясый. Аның төп бурычы –укуга аңлы караш тәрбияләү, укучы шәхесенең интеллектын үстерү. Ихтыяр көче тәрбияләүне үзмаксат итеп куярга кирәк. Шул вакытта гына укучыга тыңла, укы, теге яки бу түгәрәккә йөр дип курсәтмә бирергә кирәк булмый. Ул үзенә кирәк нәрсәне үзе эзләп табачак. Аңа юнәлеш бирү дә җитә.

...Тәрбия һәр яшь шәхеснең әхлаклы һәм социаль актив булып үсүен тәэмин итәрлек педагогик шартлар булдыруны күздә тота. Баланың күпкырлы үсешен искә алып, кешенең шәхес буларак кыйммәтен, ирекккә, бәхеткә омтылу, сәләте үсешенә хокукын таный торган педагогик технологияләр бар. Хәзер шәхескә юнәлтелгән технология зур кызыксыну уята, чөнки мәгариф системасында бала шәхесенә нык игътибар бирелә. Бу технологиядә бала шәхесе гади субъект кына түгел, ә өстенлекле субъект, ул нинди дә булса абстракт максатка ирешү чарасы түгел, ә бәлки мәгариф системасының төп максаты булып тора.

Хәзерге җәмгыятьнең нигезен һәрьяктан гармоник үсешкә ирешкән, тирәнтен фикерли алучы һәм иҗади сәләткә ия шәхес тәшкил итә. Укучыларда булган сәләт–мөмкинлекне вакытында ачыклау һәм аны максатчан үстерү – укытучы-тәрбиячenең төп бурычы ул.